**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

2021 елның 17 феврале № 37 Урыссу штп

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районында балигъ
булмаганнар һәм аларның хокукларын
яклау буенча комиссияне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында Үрнәк нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 06 ноябрендәге 995 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру турында» 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 24 сентябрендәге 798 номерлы «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында «2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» карары, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

Расларга:

1) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составын (1 нче кушымта);

2) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе Нигезләмәсен (2 нче кушымта).

Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы муниципаль районының Ютазы район Советына социаль сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы

муниципаль районы Башлыгы -

Татарстан Республикасы Ютазы

муниципаль районы Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин